| | | |
|---|---|---|
| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.06.2019 № 60-П

г. Казань

«Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты боерыгы белән расланган 2018 елның 14 ноябрендәге 47 номерлы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы карамагындагы Иҗтимагый совет турында Типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү сәбәпле боерам:

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 47 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2.1. пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«җәмгыятьтә коррупциягә түзеп тормаучанлыкны формалаштыру»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
«Иҗтимагый совет Комитет тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә аның составында 13 кеше ирекле катнашу нигезендә формалаша.»;

5.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышына Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм бәяләмәләр тәкъдим итү өчен башкарма органнар, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылган булырга мөмкин.

Иҗтимагый совет аның эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары катнашуын тәэмин итә.».

Рәис И.Н. Гущин